
# Тел күнекмәләре

Әзерләде «Салагыш гомум белем бирү мәктәбе»муниципаль бюджет белем бирү учреждениясенең мәктәпкәчә белем бирү төркеме тәрбиячесе Исмәгыйлева Алсу Сәетгалиевна.



# «Гөмбә»


**Авызны аз гына ачып,елмаерга.Җәелгән телне каты аңкауга терәп суырырга.**






# «Коймаклар»


**Елмаерга,бөтен көчкә ireннәрне җәеп,йомылган тешләрне күрсәтергә.**






# «Тәмле кайнатма»

Елмаерга.Авызны ачарга.Җәелгән телне алга чыгарып, “чынаяк” формасы ясап,өске иреннәрне яларга.








# «Тукран»

Авызны ныклап ачып,аз гына елмаерга, тел «чынаяк»формасында алга күтәрелгән: тел кырыйларын өске арткы тешләргә терәргә,телнең алгы өлешен өске алгы тешләргә,аңкауга таба күтәрергә.Бала д-д-д,т-т-т дип кабатлый тел «сикерә».





# «Керпе»


Авыз ябык.Тел очы түгәрәк “ясап”хәрәкәтләнә,һәм шул рәвешле икенче якка да хәрәкәтләнә.





# «Тешләрне чистартабыз»

Елмаерга ,авызны ачарга.Телнең очы белән,чиратлаштырып,өске һәм аскы тешләрне чистарту хәрәкәтләре ясарга.









# «Күркә»


Өске ирен буенча тел белән тиз хәрәкәтләр ясарга һәм б-б-б дип әйтергә.






# «Песи»

Иреннәр елмая,авыз ачык.Телнең очы аскы тешләргә терәлгән.Телнең сыртын күтәрергә(тау кебек).









# «Таган атыну»

Елмаерга.Авызны ачарга Башта телнең очын өске тешләр артына,аннары аскы тешләр артына хәрәкәтләндерергә.








# «Буяучы»


Иреннәр елмайган,авыз бераз ачылган.Җәелгән телнең очы белән аңкауны сыпырырга,пумала белән буяу хәрәкәте ясарга.





# «Җилкән»


Елмаеп,авызны киң итеп ачырга.Тел очын өске теш өстенә куярга.8 гә кадәр санаганчы шулай тотарга.





# «Тарак»

**Елмаеп телне тешләргә.Тешләр аша «тараган» кебек,телне алга-артка тартырга.3-4 тапкыр эшләнелә.**






# «Фил»


Иреннәрне торба формасы ясап алга сузарга,су суырып алган тавыш чыгарырга.







# «Камыр җәю»

Елмаерга.Телне аскы ирен өстенә җәеп салырга.”пә-пә-пә” дип телгә иреннәр белән бәрергә.Телнең очын тешләр белән тешләү








# «Футбол»


Авыз ябык.Тел очын әле бер,әле икенче яңакка көч белән тигезергә.Яңак кабарырга тиеш.





# «Сәгать»

Елмаерга ,авызны ачарга.Телнең очын,авызның бер почмагыннан икенче почмагына чиратлаштырып ,хәрәкәтләндерергә(сәгать теле йөргән





# «Чынаяк»

Елмаерга .Авызны зур ,киң итеп ачарга. Җәелгән телне чыгарырга һәм аңа чынаяк формасы бирергә(телнең очы һәм яннары аз гына күтәрелә).

